ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.04.2021 № 348

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 20.04.2020 ел, № 226 карарына үзгәреш кертү турында

РФ Юстиция министрлыгының 2017 елның 23 июнендәге 2754 номерлы боерыгы белән 2021 елның 17 гыйнварыннан норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы бәйсез экспертизасын үткәрүгә вәкаләтле бәйсез эксперт буларак аккредитацияләнгән Р.М. Гибатдиновның коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәсе нигезендә һәм кадрлар үзгәрешләре белән бәйле рәвештә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты оешмаларында хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контролен гамәлгә ашыру турында» 20.04.2020 ел, № 226 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2 нче кушымтада 4.1.3 пунктын алырга.

2 нче кушымтада 5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «5.2. Тикшерү нәтиҗәләре буенча хокук бозулар ачыкланган очракта, эш төркеме тарафыннан 3 көн дәвамында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә ведомство карамагындагы оешма җитәкчесен РФ Хезмәт кодексының 192, 193 статьяларында билгеләнгән тәртиптә хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен дисциплинар җаваплылыкка тарту турында тәкъдим кертелә»

Җитәкче Р.Р. Хәмзин

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
09.04.2021 ел, № 348 боерыгына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә куелган оешмаларда хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнарының һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешен ведомстволы тикшереп торуны гамәлгә ашыру буенча эшче төркем составы

<u>Эшче төркем җитәкчесе:</u>

| | |
|---|---|
| Нәфыйгина Ләйсән Мидхәт кызы | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |

<u>Эшче төркем секретаре:</u>

| | |
|---|---|
| Сатдарова Лилия Илдус кызы | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты гомуми бүлегенең кадрлар буенча баш белгече |

<u>Эшче төркем әгъзалары:</u>

| | |
|---|---|
| Усманов Салават Фәрид улы | ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары |
| Титарева Олеся Александровна | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы |
| Рәхмәтуллина Алсу Насыйх кызы | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге начальнигы |
| Фәтхетдинова Румия Минсалих кызы | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы |